# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

# КАРАР

21.11.2016 № 96

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде:

“2017 елда Кәче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

– юлларга вак таш җәю:

– Кәче авылында Сәйдәшев урамында 97 нче йорттан 120 нче йортка кадәр, Тынычлык урамында 231нче йорттан 233 нче йортка кадәр, 259 нчы йорттан 261 нче йортка кадәр, 270 нче йорттан 279 нче йортка кадәр.

- Чулпан авылында яктырткычларны ремонтлау, лампаларны алыштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга”.

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамланугa 922 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны-717, бу 77,77% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 706 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 98,71% тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 11 кеше тавыш бирде, бу 1,53% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2. “2017 елда Кәче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 75 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм

җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

– юлларга вак таш җәю:

– Кәче авылында Сәйдәшев урамында 97 нче йорттан 120 нче йортка кадәр, Тынычлык урамында 231нче йорттан 233 нче йортка кадәр, 259 нчы йорттан 261 нче йортка кадәр, 270 нче йорттан 279 нче йортка кадәр.

- Чулпан авылында яктырткычларны ремонтлау, лампаларны алыштыру;

соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга".

3.Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе — Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре — Л. И. Нурмиева